**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

17 октябрь 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Ярәп авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Ярәп авылы, Киров урамы, 9нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Ярәп авылының Беренче Май урамында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 30 минутка Ярәп авылы, Киров урамы, 9нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Иванов урамындагы йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2025 елның 11 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Ярәп авылы, Киров урамы, 9нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Киров һәм Новая урамнарындагы йортларда яшәүчләр өчен гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Ярәп авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан тыш., балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- урамнарны яктырту җайланмасы.

«РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ярәп авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова